СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 март 2023 ел** Болгар ш. **№ 28-7**

Спас муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 49-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чараларын күрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Спас муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 49-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чараларын күрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1.2 пунктның икенче абзацында, 4 пунктында, 5 пунктның икенче абзацында, 6 пунктның беренче абзацында, 7 пунктның беренче һәм өченче абзацларында «Президент» сүзен «Башлык (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

1.2.11 пунктның 1 абзацында «Президентка» сүзен «Башлыкка-(Рәискә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Спас муниципаль районы башлыгы урынбасары С.И. Тюнев